РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 13 марты Кукмара ш. № 273

Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 28 гыйнварындагы 02 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керү сәбәпле, Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 28 гыйнварындагы 02 номерлы карары белән (Кукмара муниципаль район Советының 2013 елның 8 ноябрендәге 54 номерлы, 2014 елның 25 июлендәге 36 номерлы, 2016 елның 29 мартындагы 32 номерлы, 2016 елның 26 маендагы 43 номерлы, 2016 елның 9 сентябрендәге 58 номерлы, 2016 елның 18 ноябрендәге 67 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы 78 номерлы, 2017 елның 14 июлендәге 104 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 169 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 182 номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 208 номерлы, 2019 елның 24 маендагы, 2019 елның 19 сентябрендәге 242 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Кукмара муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәт үтүгә бәйле түбәндәгеләр тыела:

1) түбәндәге очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торырга:

а) Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфасына йә Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасына сайланса яисә билгеләп куелса, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куелса;

б) муниципаль вазыйфага сайланса яисә билгеләп куелса;

в) һөнәр берлеге органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органында түләүле сайланулы вазыйфага сайланса;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерциячел оешма белән идарә итүдә яисә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашу;

б) актта билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең съездында (конференцияләрдә) яисә гомуми җыелышта катнашудан тыш) катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманың гамәлгә куючысы вәкаләтләрен башкару яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актларга таянып, муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3.) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

4) үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган йә аңа турыдан-туры буйсынган яисә аның контрольлегендә булган җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә өченче затлар эшләре буенча ышанычлы зат яисә вәкил булырга, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса;

5) физик һәм юридик затлардан вазыйфаи дәрәҗәгә бәйле рәвештә яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата кызыксындыру, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачулар, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләр) алырга. Муниципаль хезмәткәрнең протокол чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле алынган бүләкләре муниципаль милек булып танылa һәм, Россия Федерациясенең Гражданлык кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган җирле үзидарә органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә акт буенча тапшырыла. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

6) физик һәм юридик затларның акчалары исәбеннән командировкаларга йөрергә, җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, сайлау комиссияләре белән, шулай ук чит илләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, халыкара һәм чит дәүләтләрнең коммерциячел булмаган оешмалары белән үзара килешүе нигезендә гамәлгә ашырыла торган командировкалардан тыш;

7) вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булмаган максатларда матди-техник, финанс һәм башка тәэмин итү чараларын, башка муниципаль мөлкәтне файдаланырга;

8) үзенә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә мәгълүм булган федераль законнар нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә караган белешмәләрне яисә хезмәт мәгълүматын фаш итәргә яисә муниципаль хезмәткә бәйле булмаган максатларда файдаланырга;

9) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре эшчәнлегенә карата халык алдында фикерләр әйтүгә, фикер йөртүләргә һәм бәя бирүгә ирек бирергә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, әгәр болар аның вазыйфаи бурычларына кермәсә;

10) Кукмара муниципаль районы башлыгының язмача рөхсәтеннән башка чит илләрнең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен (фәнни дәрәҗәләрдән

тыш) алырга, әгәр күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара эшләү аның вазыйфаи бурычларына керсә;

11) сайлау алды агитациясе, шулай ук референдум мәсьәләләре буенча агитация өчен вазыйфаи нигезләмә өстенлекләреннән файдаланырга;

12) вазыйфаи дәрәҗәсен сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр мәнфәгатьләрендә файдаланырга, шулай ук халык алдында күрсәтелгән берләшмәләргә үзенең мөнәсәбәтен муниципаль хезмәткәр буларак белдерергә;

13) җирле үзидарә органнарында, башка муниципаль органнарда сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр структураларын (һөнәр берлекләре, шулай ук ветераннар һәм иҗтимагый үзешчән сәнгатьнең башка органнарыннан тыш) төзергә яисә күрсәтелгән структураларны төзүдә ярдәм итәргә;

14) хезмәткә кагылышлы бәхәсләрне җайга салу максатларында вазыйфаи бурычларын үтәүне туктатырга;

15) идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, чит дәүләтләрнең хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш йөртүче структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

16) яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) язмача рөхсәтеннән башка бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит дәүләт оешмалары, чит дәүләт гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның акчалары исәбеннән финанслана торган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.

1.2. 7.2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2.3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм кире алу тәртибе «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт турындагы законнарда билгеләнә»;

1.3. 7.3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«7.3.9. Әлеге Нигезләмәнең 3.3, 3.6 һәм 7.2 пунктларында каралган җәзалар муниципаль хезмәткәрнең коррупциячел хокук бозуы турында мәгълүмат кергән көннән алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәр вакытлыча эшкә сәләтсез булган чорны, аның отпускта булуын исәпләмичә, һәм коррупциячел хокук бозу башкарылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытларга җинаять эше буенча производство вакыты керми.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район Башлыгы Димитриев С. Д.